Гражданнарны наркотикларга каршы торырга өйрәтү һәм тәрбияләү – наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауның наркомания белән авыруның сәбәпләре, чагылышлары, катлауланулары, медик һәм социаль яктан тискәре нәтиҗәләре турында, наркотик чаралар, психотроп матдәләр куллануга җәлеп ителүгә каршы тору ысуллары турында белем таратуга, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен алып бару күнекмәләрен булдыруга юнәлдерелгән мәҗбүри состав өлеше.

2 статья. **Татарстан Республикасында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауны хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау мәсьәләләре буенча үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә (чыгарырга) хокуклы.

3 статья. **Әлеге Законның максатлары һәм бурычлары**

1. Әлеге Законның максаты наркоманиянең һәм токсикоманиянең барлыкка килүен һәм таралуын кисәтүгә, психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланучы затлар санын һәм психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллану аркасында җәмгыятьтәге югалтуларны киметүгә юнәлдерелгән чаралар системасын булдырудан гыйбарәт.

2. Әлеге Законның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләүнең нигезләрен билгеләү;

2) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау чараларын финанслау тәртибен билгеләү;

3) психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллануны профилактикалауның, психоактив матдәләр кулланучыларны дәвалауның, психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланудан дәваланган затларны медик-социаль һәм социаль реабилитацияләүнең төп юнәлешләрен билгеләү.

**4 статья. Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауның төп принциплары**

Татарстан Республикасы территориясендә наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) законлылык;

2) гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

3) затларны психоактив матдәләрне законсыз куллануга җәлеп итүне кисәтүгә юнәлдерелгән башлангыч психологик, социаль йогынтының, белем бирү йогынтысының өстенлеге;

4) наркотик чаралар куллануны кисәтүгә, психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланучы затларга медицина һәм реабилитация ярдәме күрсәтүгә индивидуаль якын килү;

5) комплекслы максатчан йогынты ясау, профилактикалауны шәхси, гаилә һәм социаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашыру;

6) балигъ булмаганнар арасында психоактив матдәләрне законсыз куллануны профилактикалауның, наркоманияне һәм токсикоманияне кисәтү, наркотик чаралар кулланучы балигъ булмаганнарга медицина һәм реабилитация ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашырганда аерым якын килүне куллануның мөһимлеген тану;

7) законнар нигезендә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә профилактикалау субъектлары эшчәнлегендә хәбәрдарлык;

8) психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллануны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыручы йә шундый чараларны гамәлгә ашыруда финанс ярдәме күрсәтүче оешмалар эшчәнлегенә, әлеге оешмаларның оештыру-хокукый рәвешенә карамастан, дәүләт ярдәме күрсәтү.

**2 бүлек. Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау чараларын гамәлгә ашыручы дәүләт органнары вәкаләтләре**

**5 статья. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф һәм белем бирү учреждениеләре өлкәсендәге органнарының наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

1. Башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендәге органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне, токсикоманияне профилактикалау һәм балалар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен булдыру буенча программаларны һәм методикаларны эшләү һәм белем бирү учреждениеләре тәҗрибәсенә кертү;

2) уку йортларында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча белгечләрнең квалификациясен күтәрүне оештыру;

3) гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына, шул исәптән психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы

затларны ачыклау өчен, профилактик медицина тикшерүләре уздыруны оештыру һәм аның барышын тикшереп тору;

4) социаль дезадаптацияне һәм девиантлыкны кисәтү максатларында үсешләрендә яки үз-үзләрен тотышларында тайпылышлары булган балаларга һәм яшүсмерләргә психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтүче белем бирү учреждениеләре челтәрен үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;

5) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау һәм белем бирү учреждениеләре өчен профилактика өлкәсендә белгечләр әзерләү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы югары уку йортларының Ректорлар советы һәм Татарстан Республикасы махсус урта уку йортларының Директорлар советы белән үзара мөнәсәбәттә булу;

6) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Белем бирү учреждениеләре вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча программаларны һәм методикаларны тормышка ашыру;

2) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау өчен гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына профилактик медицина тикшерүләре уздыруны оештыру;

3) социаль-куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны ачыклау һәм алар белән индивидуаль профилактик эш уздыру;

4) социаль дезадаптацияне һәм девиантлыкны кисәтү максатларында үсешләрендә, укуларында яки үз-үзләрен тотышларында проблемалары булган балигъ булмаганнарга, шулай ук аларның ата-аналарына яки бүтән законлы вәкилләренә социаль-психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү;

5) белем бирү учреждениеләре биналарында һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә психоактив матдәләр куллану һәм тарату фактларын булдырмауны үз компетенциясе чикләрендә тәэмин итү;

6) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 6 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәтен, спорт һәм туризмны гамәлгә ашыру өлкәсендәге органнарының һәм учреждениеләрнең наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

1. Башкарма хакимиятнең яшьләр сәясәтен, спорт һәм туризмны гамәлгә ашыру өлкәсендәге органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) балаларга һәм яшьләргә юнәлдерелгән наркотикларга каршы профилактика программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) сәламәтләндерүне, ял итүне, эш белән тәэмин итүне, физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүне дә кертеп, буш вакытны оештыру, балаларга һәм яшьләргә юридик, психологик һәм башка ярдәм күрсәтү, психоактив матдәләр куллануны туктаткан яшьләрне социаль реабилитацияләүгә булышлык итү буенча махсуслаштырылган учреждениеләр челтәрен үстерү;

3) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән волонтерлык хәрәкәтенә ярдәм итү;

4) эшчәнлекләре яшьләр арасында психоактив матдәләр куллануны кисәтүгә, яшьләрнең буш вакытын, эш белән тәэмин ителүен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга юнәлдерелгән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен һәм оешмаларын оештыру-методик яктан тәэмин итү;

5) яшьләр арасында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендә белгечләр әзерләүне һәм аларны яңадан әзерләүне оештыру;

6) иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, дини конфессияләр белән үз компетенцияләре чикләрендә үзара мөнәсәбәтләрне оештыру;

7) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Яшьләр сәясәтен, спорт һәм туризмны гамәлгә ашыру буенча учреждениеләр вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркотикларга каршы профилактика программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) балаларга һәм яшьләргә психологик, юридик һәм башка ярдәм күрсәтү;

3) яшьләргә хезмәт күнекмәләре алуда һәм эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү;

4) балаларны һәм яшьләрне физик тәрбияләү һәм аларның иҗади сәләтләрен үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

7 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органнарының һәм учреждениеләрнең наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

1. Башкарма хакимиятнең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча программаларны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) дәвалау-профилактика һәм дарухәнә учреждениеләрендә наркотик чараларны, психотроп, көчле тәэсир итүче матдәләрне һәм аларның прекурсорларын саклауның, аларны юнәтүнең, исәпкә алуның, җибәрүнең, сатуның, куллануның билгеләнгән кагыйдәләрен бозу фактларын ачыклау максатларында наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше өлкәсендә вәкаләтле дәүләт органнары белән үзара мөнәсәбәттә булу;

3) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау һәм исәпкә алу эшен оештыру;

4) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча кадрлар әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

5) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны исәпкә алу буенча күрсәткечләр базасын законнар нигезендәге вәкаләтләр чикләрендә алып бару;

6) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендә сәламәтлек саклау учреждениеләре вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау, исәпкә алу һәм тикшерү;

2) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны дәвалауны гамәлгә ашыру һәм медик-социаль реабилитацияләүдә катнашу;

3) тиешле дәвалау уза торган балигъ булмаганнарның ата-аналарына һәм башка законлы вәкилләренә консультация ярдәме күрсәтү;

4) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны исәпкә алу буенча күрсәткечләр базасын алып бару;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

8 статья. **Эчке эшләр органнарының наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр органнары вәкаләтләренә федераль законнар нигезендә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча программаларны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) наркотик чараларның, психотроп һәм көчле тәэсир итүче матдәләрнең законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне һәм административ хокук бозуларны ачыклау һәм кисәтү; аларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны билгеләү;

3) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны сәламәтлек саклау органнары белән берлектә ачыклау һәм аларны исәпкә алу;

4) балалар һәм яшьләр арасында наркоманияне һәм токсикоманияне башлангыч профилактикалау буенча чаралар уздыру;

5) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларга карата индивидуаль профилактика чараларын гамәлгә ашыру;

6) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

9 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең халыкны социаль яклау, эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендәге органнарының һәм учреждениеләрнең наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

1. Башкарма хакимиятнең халыкны социаль яклау, эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендәге органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) халыкны социаль яклау учреждениеләренең наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлегенә оештыру-методик яктан җитәкчелек итү;

2) социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ гражданнар, бигрәк тә балигъ булмаганнар өчен, махсуслаштырылган учреждениеләр, шулай ук гаиләгә һәм балаларга социаль һәм психологик ярдәм күрсәтү учреждениеләре челтәрен үстерү;

3) социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ балигъ булмаганнарны социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә җибәрү;

4) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Халыкны социаль яклау, эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү учреждениеләре вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланучы әгъзалары булган гаиләләрне ачыклау һәм аларга социаль ярдәм күрсәтү;

2) күзәтүчесез һәм караучысыз калган балигъ булмаганнарга, шул исәптән психоактив матдәләрне кулланучыларга, аларның балигъ булмаганнарны тәрбияләү һәм карап тоту буенча үз бурычларын тиешенчә үтәмәүче, йә аларның тәртибенә тискәре йогынты ясаучы, йә алар белән рәхимсез мөгамәләдә булучы ата-аналарына яисә законлы вәкилләренә карата индивидуаль профилактика эшен оештыру;

3) психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланудан дәвалану курсы үткән затларга эшчәнлек төрен һәм һөнәр сайлауда, аларны эшкә урнаштыруда, һөнәри әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

4) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

10 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге органнарының һәм учреждениеләрнең наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге органнары һәм учреждениеләр вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) наркотикларга каршы чараларны һәм акцияләрне (наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән массакүләм чаралар, күргәзмәләр оештыруны, кинофильмнар төшерүне дә кертеп) оештыруда һәм уздыруда катнашу;

3) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен булдыру өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы башка органнар, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлекне һәм үзара мөнәсәбәтләрне киңәйтү;

4) мәдәният оешмалары (учреждениеләре) биналарында һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә психоактив матдәләр куллану һәм тарату фактларына юл куймауны үз компетенциясе чикләренә тәэмин итү;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге органнары һәм учреждениеләр наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау максатларында гражданнарга мәгълүмати-агарту һәм мәдәни-ял эшчәнлеген гамәлгә ашыру юлы белән аларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә, аларны үзебезнең һәм дөньякүләм мәдәният кыйммәтләренә якынайтуда, ял вакытларын

тәэмин итүдә үз компетенциясе чикләрендә ярдәм күрсәтәләр, шулай ук законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

11 статья. **Җирле үзидарә органнарының наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарының наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча муниципаль программаларны гамәлгә ашыруда катнашучы оешмаларның эшчәнлеген координацияләү;

3) психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы гражданнар белән профилактика, реабилитацияләү һәм тәрбия эшен алып баручы муниципаль учреждениеләрне үстерү;

4) балаларның һәм яшьләрнең хезмәт белән тәэмин ителүе системасын үстерүгә ярдәм итү;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

12 статья. **Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауда башка катнашучылар**

1. Татарстан Республикасында теркәлгән иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, коммерциячел һәм дини оешмалар дәүләт органнары тарафыннан уздырыла торган профилактика чараларында ихтыярый нигездә катнашалар.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар законнар нигезендә үзләренең профилактика чаралары комплексын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга хокуклы.

3 бүлек. **Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлеген координацияләү**

13 статья. **Татарстан Республикасы Президенты**

Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары белән наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлеген җайга сала, Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан

Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары белән һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары белән, һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара мөнәсәбәтләрен оештыра.

Татарстан Республикасы Президенты:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели;

2) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итә;

3) федераль законнар нигезендә оештырыла торган Татарстан Республикасында наркотикларга каршы көрәш комиссиясенә җитәкчелек итә;

4) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

14 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге сәясәтне гамәлгә ашыру, федераль башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара мөнәсәбәтләрне оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) республика программаларын эшли һәм аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

2) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган бюджет чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп тора;

3) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар кабул итә;

4) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруда җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтә.

15 статья. **Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия**

1. Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия Россия Федерациясе Президенты указы нигезендә төзелә. Наркотикларга каршы комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Президенты указы белән раслана.

2. Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы көрәш өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген җайга сала.

16 статья. **Муниципаль берәмлекләрдә наркотикларга каршы ведомствоара комиссияләр**

1. Муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында муниципаль берәмлекләрнең наркотикларга каршы ведомствоара комиссияләре төзелергә мөмкин.

2. Муниципаль берәмлекләрдә наркотикларга каршы ведомствоара комиссияләр составына сәламәтлек саклау, мәгариф, эчке эшләр, хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, яшьләр эшләре һәм спорт, мәдәният органнары җитәкчеләре керә. Кирәк булганда күрсәтелгән комиссияләр составына муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан федераль дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләре, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар вәкилләре кертелергә мөмкин. Муниципаль берәмлекләрдә наркотикларга каршы ведомствоара комиссияләр җитәкчеләре булып муниципаль берәмлекләр башлыклары тора.

3. Муниципаль берәмлекләрдә наркотикларга каршы ведомствоара комиссияләрнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) наркотикларга каршы федераль һәм республика законнарының, шулай ук Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия карарларының үтәлешен тәэмин итү;

3) Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия өчен тәкъдимнәр әзерләү;

4) наркотикларга каршы муниципаль программаларны гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән акчаларның максатчан һәм нәтиҗәле тотылуын тикшереп тору.

17 статья. **Наркотикларга каршы программалар**

1. Халыкка комплекслы профилактика йогынтысын тәэмин итү, дәвалау, реабилитацияләү һәм хокук саклау эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасында наркотикларга каршы республика һәм ведомство программалары эшләнә һәм гамәлгә ашырыла.

2. Республика программасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эшләнә, раслана һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан финанслана.

3. Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары наркотикларга каршы республика программасын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән һәм төп эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән финанслана торган наркотикларга каршы үз программаларын һәм планнарын эшли алалар.

4. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары җирле бюджет акчаларыннан финанслана торган наркотикларга каршы программаларны эшләргә һәм гамәлгә ашырырга мөмкин.

4 бүлек. **Психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау һәм исәпкә алу**

18 статья. **Оешмалар хезмәткәрләре арасында психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау**

1. Хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри һәм (яисә) даими медицина тикшерүләрен уздыру барышында федераль законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә аларның психоактив матдәләр куллануына карата медицина таныклавы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге башкарма органы системасының наркология учреждениеләрендәге махсуслаштырылган исәпкә куюлар буенча тикшерү уздырыла.

2. Эш бирүче федераль законнар нигезендә хезмәткәргә алдан эшкә урнашканда һәм даими рәвештә психоактив матдәләр куллануга карата медицина таныклавы узуның мәҗбүрилеген билгеләргә мөмкин.

3. Бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә таныклау уздыру тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән, башка милек рәвешендәге оешмалар хезмәткәрләренә шул оешмалар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

19 статья. **Гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына медицина тикшерүе уздыру барышында психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау**

1. Гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына медицина тикшерүе уздыру барышында федераль законнар нигезендә аларның психоактив матдәләр куллануына карата медицина таныклавы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге башкарма органы системасының наркология учреждениеләрендәге махсуслаштырылган исәпкә куюлар буенча тикшерү уздырыла.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга таныклау уздыру Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5 бүлек. **Наркотикларга каршы өйрәтү, тәрбияләү һәм пропаганда**

20 статья. **Гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларын, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларын наркотикларга каршы тәрбияләү**

1. Милек рәвешенә бәйсез рәвештә гомуми урта белем бирү мәктәпләренең, башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләренең, махсус урта һәм югары уку йортларының белем бирү программаларына укучыларга һәм студентларга

психоактив матдәләр куллануның зарарлы нәтиҗәләрен, наркотикларның законсыз әйләнешенә бәйле хокук бозулар кылуның хокукый нәтиҗәләрен аңлата торган уку элементлары һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау кертелергә тиеш.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән уку йортларының тәрбия эше планында психоактив матдәләр куллануны профилактикалауга һәм сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен булдыруга юнәлдерелгән тематик дәресләрне һәм башка чараларны даими рәвештә уздыру, шулай ук балигъ булмаганнарның ата-аналары яки бүтән законлы вәкилләре катнашында махсус дәресләр уздыру күздә тотылырга тиеш.

21 статья. **Гаиләдә наркотикларга каршы өйрәтү һәм тәрбияләү**

Гаиләдә наркотикларга каршы өйрәтү һәм тәрбияләү Россия Федерациясе Гаилә кодексы һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары таләпләре нигезендә балигъ булмаганнарның ата-аналары яки бүтән законлы вәкилләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

22 статья. **Балаларның һәм яшьләрнең буш вакытын оештыру өлкәсендә наркотикларга каршы тәрбияләү**

1. Балаларның һәм яшьләрнең буш вакытын тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрнең наркотикларга каршы эшчәнлеген оештыру һәм мәгълүмати-методик яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм органнарына йөкләнә.

2. Балаларда һәм яшьләрдә психоактив матдәләр кулланугa нәфрәт тудыру, аларда сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен булдыру максатларында яшьләр эшләре, физкультура һәм спорт органнары һәм учреждениеләре психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланугa каршы көрәш буенча профилактика эшен гамәлгә ашыручы яшьләр оешмалары һәм хәрәкәтләре оештыралар һәм аларга ярдәм күрсәтәләр.

23 статья. **Наркотикларга каршы пропаганда**

1. Наркотикларга каршы пропаганда наркотикларга каршы программаларны гамәлгә ашыруда катнашучы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар тарафыннан, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Наркотикларга каршы республика һәм муниципаль программаларда наркотикларга каршы пропаганда материалларын әзерләүгә һәм урнаштыруга финанс чаралары бүлеп бирү күздә тотыла.

3. Гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары булган массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре үзләре тарата торган еллык реклама күләменең 5 процентыннан да ким булмаган күләмдә социаль реклама хокукларында наркотикларга каршы юнәлештәге материаллар урнаштырырга тиешләр.

4. Наркотикларга каршы пропаганда шулай ук китаплар, брошюралар, буклетлар һәм башка көндәлек булмаган матбугат басмаларын бастырып чыгару һәм тарату юлы белән гамәлгә ашырыла ала.

Тышкы реклама, мәгълүмат һәм бизәү кулланылып наркотикларга каршы пропаганда ясау сурәтләрне һәм язуларны, шул исәптән наркотикларга каршы символиканы, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның түбәләрендә, тышкы диварларында һәм башка конструкция элементларында яки алардан читтә, транспорт чараларында корыла һәм урнаштырыла торган реклама конструкцияләрендә урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла, һәм ул Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан урнаштырыла торган социаль рекламаның еллык гомуми күләменең 10 процентыннан да ким булмаган өлешен тәшкил итәргә тиеш.

## 6 бүлек. **Психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны дәвалау, медик-социаль һәм социаль реабилитацияләү**

### 24 статья. **Наркологик ярдәм күрсәтү**

1. Психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларга наркологик ярдәм эшчәнлекнең күрсәтелгән төренә тиешле лицензия алган сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Наркологик ярдәм психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларга амбулатор һәм стационар шартларда консультация-диагностика, дәвалау һәм реабилитацияләү ярдәмен күрсәтүне үз эченә ала.

3. Наркологик ярдәм, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, затның ихтыярый мөрәҗәгате яисә аның ризалыгы белән күрсәтелә.

4. Унбиш яше тулмаган яисә федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә хокуктан файдалануга сәләтсез дип табылган затларга наркологик ярдәм, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, аларның ата-анасының яисә башка законлы вәкилләренең үтенече йә ризалыгы белән күрсәтелә.

5. Наркомания һәм токсикомания белән авыручыларны дәвалау бары тик дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системалары учреждениеләрендә сәламәтлек саклау өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы рөхсәт иткән чараларны һәм ысулларны кулланып гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органы сәламәтлек саклауның наркология учреждениеләре эшчәнлеген тикшереп тора.

### 25 статья. **Психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны медик-социаль реабилитацияләү**

1. Психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны медик-социаль реабилитацияләү, оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, тиешле лицензиясе булган медицина учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны медик-социаль реабилитацияләүне гамәлгә ашыру өчен максатлары дәвалауның уңай нәтиҗәләрен ныгыту булган наркологик реабилитация үзәкләре оештырыла.

3. Наркологик реабилитация үзәкләренең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) наркоманиядән һәм токсикоманиядән дәвалану курсы узган затларга медик-психологик ярдәм күрсәтү;

2) сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен булдыру;

3) психоактив матдәләрне куллану рецидивларын профилактикалау максатларында психоактив матдәләргә бәйлелек булган затларның гаилә әгъзаларын федераль законнарда каралган тәртиптә реабилитацияләү чараларында катнашырга җәлеп итү.

4. Психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллануны профилактикалау максатларында наркологик реабилитация үзәкләре шулай ук түбәндәгеләрне гамәлгә ашыралар:

1) авырулар наркологик реабилитация үзәкләрендә булган вакытта күрсәтелүче ярдәмнең нәтиҗәлелеген анализлауны;

2) рецидивларны профилактикалау һәм реабилитация узган затларны реабилитация программаларындагы эшкә җәлеп итү өчен алар белән элемтәдә торуны;

3) наркологиядән реабилитация үзәкләре структурасыннан тыш реабилитация төркемнәре оештыруда катнашуны;

4) реабилитация курсы узган затларга эшкә урнашу, торак урыннар белән тәэмин итү, хокуктан файдалану сәләтен торгызу, пособиеләр алу мәсьәләләре буенча комплекслы социаль ярдәм күрсәтү оешмалары һәм учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлекне;

5) кызыксынучы юридик һәм физик затларны реабилитация программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итү, психоактив матдәләрне законсыз куллануга китерүче сәбәпләр һәм шартлар, аларны бетерү мөмкинлекләре турында мәгълүмат тарату максатларында наркологик реабилитация үзәкләренең эше хакында җәмәгатьчелеккә хәбәр итүне.

5. Наркологик реабилитация үзәкләренә кабул итү наркологик дәвалау учреждениеләре юлламасы буенча ихтыярый нигездә гамәлгә ашырыла.

### 26 статья. **Психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланудан дәвалану курсы һәм медик-социаль реабилитация узган затларны социаль реабилитацияләү**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендәге органы психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланудан дәвалану курсы һәм медик-социаль реабилитация узган затларны социаль реабилитацияләү буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

2. Иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, юридик һәм физик затлар эшкә урнаштыруда булышлык итү, психологик һәм башка төрле ярдәм күрсәтү юлы белән, законнарда тыелмаган башка ысуллар белән, шул исәптән түләүле нигездә, социаль реабилитацияләүдә катнашалар. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендәге органнары аларның дәвалану курсы һәм медик-социаль реабилитацияләү үткән затларны социаль реабилитацияләү буенча эшчәнлекләрен кызыксындыру буенча чаралар комплексын эшлиләр һәм гамәлгә ашыралар.

7 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

27 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 29 октябре
№ 50-ТРЗ